**КАЗ ӨМӘСЕ**

Каз өмәсе, каз өмәсе,
Каз йолкыйлар апалар.
Бала  - чагалар узыштан
Куыгын кабарталар.

*Кушымта:*
Кыйгак-кыйгак, кыйгак-кыйгак,
Уйнап көләсе!
Бигрәк күңелле шул
Каз өмәсе!

Әбиләр коймак пешерә,
Манып каз майларына.
Гармун көенә җырлыйлар
Кызлар үз җайларына.

Эш беткәч, өстәлгә килә
Каз бәлеше, коймаклар.
Каз өмәсен ишетеп тагын
Кайтып төшә кунаклар.

Менә шулай бик күңелле
Каз өмәләре үтә.
Күчтәнәчләр төяп кайткан
Кунаклар кире китә.